**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 6 июнендәге 2330 номерлы карары

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 1914 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут урнаштыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалы булган Казан электр челтәрләренең Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 1914 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут урнаштыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә таянып карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 1914 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешендә ачык сервитут урнаштыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пункт гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктча гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**